# Sarman

Tatar-Bashkort Folk Song

Recorded by Masguda Shamsutdinova


Moderato



©


17
19
21
23
25
27
29
31
33


35
3
37
39
41
43
45
47
49
51




Sarman is Sikh/Punjabi Boy name and meaning of this name is "Pure Heart"

Сандугачлар кунып кайда сайрый?
Сарман буйларында тирәктә, шул,
Сарман буйларында тирәктә.
Синә булган яшьлек мәхәббәтем
Үрелеп чәчәк ата йөрәктә.

Сарман буйларыннан үткән чакта,
Тыңларсыңмы, җырлар җырлармын, шул,
Тыңларсыңмы, җырлар җырлармын.
Күзләреңне тутырып карарсыңмы,
Зәңгәр таудан яулык болгармын.

Сарман буйларында яшел алан,
Печәннәре җитәр бер заман, шул,
Печәннәре җитәр бер заман.
Бергә яшәүләре бик күңелле,
Әмма аерылышу бик яман.

Сарман атамасы тарихи, тарихи-географик, географик-статистик хезмәтләрдә еш кабатлана.
1870 елдагы мәгълүматларга караганда, Сармандагы 168 хуҗалыкта
536 ир-ат һәм 526 хатын-кыз яшәгән. Анда типтәрләр һәм татарлар гомер иткән.
Авылда мәчет, мәдрәсә һәм ике су тегермәне эшләгән.
Сарман атамасы, аның килеп чыгышы, тамырлары чал тарих тирәнлегенә барып тоташа.
Сарманлылар үзләре Сарманны Сарман бабай нигезләгән дип исәплиләр.
Бу атама, безнең карашыбызча, кыпчак (нугай) этнонимы (кабилә-кавем исеме) «сарман»га бәйләнешле. Этноним хәзер топоним, гидроним һәм антропоним формасында ныгып калган.
Урта Жуз казакълары килеп чыгышында да «сарман» этнонимы катнашкан. Сарман атамасы Павлодар өлкәсендә очрый. Атама төрекмән топонимиясендә дә урын алган. Сарман кабилә-кавемнәренең бер ишеләре — казакъ, икенчеләре — төрекмән, өченчеләре татар халкы оешуга өлеш керткән. М. Әхмәтҗанов хезмәтләреннән күренгәнчә, татар шәҗәрәләрендә Сарманай исеме табыла. Сарман, Сарманай һәм Сарманаев фамилияләре татарларда, керәшеннәрдә һәм Пермь татарларында да очрый. Мари Иле Республикасының Таулы Мари районында Сарман-Сола исемле авыл бар. Мари галимнәре бу атаманың шәхес исеме Сарманга һәм татар телендә кайчандыр актив кулланылышта булып, авыл мәгънәсен бирә торган, ә хәзер искергән «сала» сүзе кушылып ясалган дип уйлыйлар.
1716—1717 елларга караган чыганакларда һәм тарихи материалларда мари галиме С.Я. Черных Сарманайко исемен очрата. Википедия